ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**06.09.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2713**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының юл хәрәкәте иминлеге комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 11 сентябрендәге 2354 номерлы карары белән (2020 елның 09 июнендәге 1040 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының юл хәрәкәте иминлеге буенча комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2021 елның 21 декабрендәге «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 414-ФЗ номерлы Федераль закон, 2023 елның 26 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының юл хәрәкәте иминлеге комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 11 сентябрендәге 2354 номерлы карары белән (2020 елның 09 июнендәге 1040 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының юл хәрәкәте иминлеге буенча комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәис) сүзләренә алмаштырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин